**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ СРЕДНЕДЕВЯТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА ДЕВЯТОВО АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422614 с.Среднее Девятово
ул. Сергеева, д.9
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

422614 а.Урта Девятово
Сергеев урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

**2021 елның 24 августы** **29 номерлы**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге Советының 2015 елның 30 октябрендәге «Җир салымы турында " гы 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Урта Девятово авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» 2015 елның 30 октябрендәге 36 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге советы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата 0,001 процент күләмендә җир салымы ставкасын билгеләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Интернетның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда (htth:/pravo.tatarstan.ru), Лаеш муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (htth://laishevo.tatarstan. ru) һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге Советының Икътисадый үсеш һәм план-бюджет комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Урта Девятово**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **О.Н.Чумарова.**